**ПРИНЯТО**
на заседании педагогического совета
Протокол № 1 от 26.08.2022

**УТВЕРЖДЕНО**
Приказом заведующего МБДОУ «Детский сад комбинированного вида «Солнышко» города Буинска Буинского муниципального района Республики Татарстан»
От 26.08.2022 № 72

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН
ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

Сертификат: 3343C3A556B7F51FD022F1A07D0EFEFADD12877B
Владелец: Абузярова Энже Загретдиновна
Действителен: с 30.11.2021 до 02.03.2023

# Рабочая программа по обучению русскоязычных детей татарскому языку муниципального бюджетного дошкольного образовательного учреждения «Детский сад комбинированного вида «Солнышко» города Буинска Буинского муниципального района Республики Татарстан» на 2022-2023 учебный год

Воспитатель по обучению детей
татарскому языку Гиниятуллина Д.Р.

# Эчтәлек


1. Аңлатма язуы ........................................................................................................ 3
2. ФДС тормышка ашыру ............................................................................................ 5
3. Лингвистик материал сайлау схемасы. Тиешле лингвистик материал .................................... 6
4. “Минем өем” проекты буенча тематик план (Уртанчылар төркеме) ...................................... 12
5. “Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча тематик план (Зурлар төркеме) ............................. 16
6. “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча тематик план (Мәктәпкә әзерлек төркеме) ............................................................................................ 20
7. Диагностика. Балаларның татар телен белү дәрәҗәсен билгеләү өчен биремнәр ..................
9. Рус төркемендә тәрбияләнүче татар балаларының ана телен үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү (уртанчылар төркеме)........................................................................................ 30
10. Кулланылган әдәбият ........................................................................................... 31

## Аңлатма язуы

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән кабул ителгән 2010 – 2015 елларда мәгарифне үстерү Стратегиясе (30.12.2010, № 1174) – “Киләчәк” программасында мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен Федераль дәүләт стандартлары таләпләренә җавап бирә алырдай укыту-методик комплектлар (УМК) булдыру бурычы куелган. Балалар бакчаларында балаларны татар теленә өйрәтү, аларның сөйләм телен үстерү өчен заман таләпләренә җавап бирерлек итеп төзелгән эзлекле, максатчан методик әсбаплар белән тәэмин итү зарур. Әлеге максаттан ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы карары белән яңа укыту-методик әсбаплар төзелде.

Балалар бакчасында рус балаларына татар теле өйрәтү буенча эш программасы (алга таба – Эш программасы) - мәктәпкәчә тәрбия һәм белем учреждениесендә рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә, үзара һәм өлкәннәр белән аралашырга өйрәтү, төрле яктан үсеше өчен мөмкинлекләр тудыруга юнәлтелгән документ булып тора. Эш программасы Федераль дәүләт белем стандартына (ФГОС) нигезләнеп төзелде, максат һәм бурычларны, көтелгән нәтиҗәләрне, белем бирү процессын оештыруны билгели.

Эш программасы мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив -хокукый актлар нигезләмәләренә көйләнгән.

**Федераль җирлегендә:**

- 29.12.2012 елдан № 273-ФЗ « Россия Федерациясенең белем бирү турында» Федераль законы;
- Мәктәпкәчә мәгарифнең Федераль дәүләт белем стандарты (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 елның 17 октябрендә 1155 нче номерлы боерык нигезендә расланган);
- СП 2.4.3648-20 « Балалар һәм яшьләрне тәрбияләү, укыту, ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларына карата санитар-эпидемиологик таләпләр” раслау турында Россия Федерациясе баш дәүләт табибы 2020 ел 28 сентябрьеннән №28 нчы номырлы карары; СанПиН 2.3/2.4.3590-20 Россия Федерациясе Баш дәүләт табибының 27.10.2020 ел, №32 карары "Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр»; Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының 2021 елның 28 гыйнварындагы 2 номерлы карары белән расланган СанПин 1.2.3685-21 номерлы санитар кагыйдәләре "Кеше өчен яшәү мохите факторларының иминлеген һәм (яисә) зыянсызлыгын тәэмин итүгә гигиеник нормативлар һәм таләпләр";
- “Мәктәпкәчә мәгарифнең белем бирү эшчәнлеген төп гомуми белем бирү программалары нигезендә оештыру һәм тормышка ашыру” (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 ел 30 август 1014 нче номерлы

боерыгы);

**Төбәк җирлегендә:**

- Татарстан Республикасының 2013ел 22 июль 68-ЗРТ номерлы «Белем бирү турында» Законы;
- Татарстан Республикасының "Татарстан Республикасында Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм башка телләр турында" Законы;

**Мәктәпкәчә белем учреждениесе җирлегендә:**

- МБМББУнең төп белем бирү программасы турында нигезләмәсе;

Эш программасы өч бүлектән (программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр, эчтәлекле, тематик планнан) тора, белем бирү өлкәләре буенча куелган бурычларны күздә тота. Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларны татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләрен режим вакытларын үз эченә ала.

## I. Программа үзләштерүдә көтелгән нәтиҗәләр:

### 1.1 Максатчанлык

Информацион – коммуникатив технологияләр, уен – ситуацияләр, күргәзмәлелек кулланып, тел өйрәтү, аралашу теләге тудыру программаның төп максаты булып тора.

**Бурычлар:** 1. Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү.

2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту; диалогик һәм монологик сөйләмне, хәтер, зиһен сәләтләрен үстерү.
3. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен, бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары, әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

## II Эчтәлекле

Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына, сөйләм барлыкка килү концепциясенә (Л.С.Выготский, В.В.Давыдов, Е.И.Пассов, П.Я.Гальперин), гамәли эшкәртмәләр һәм методик киҗәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклый торган норматив-хокукый актлар, документларга нигезләнә. Программа зурлар һәм мәктәпкә әзерлек төркем балаларына диагностик тикшерү уздырган нәтиҗәләргә таянып тезелгән.

## 2.1. Уртанчылар төркеме (4-5 яшь)
## “Минем өем” проекты
## Режим вакытында уен эшчәнлегенең бурычлары

1.Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, иң якын кешеләре, уенчыклар, ашамлыклархисабына сүз байлыгын арттыру.

2.Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү, тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә белүләренә ирешү.

3.Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белү күнекмәләрен үстерү, куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтару күнекмәләрен үстерү.

## Режим вакытында уен эшчәнлегенең эчтәлеге

**Уртанчылар төркеме** татар булмаган балалар татар телен режим вакытында атнага ике тапкыр төзелгән циклограмма буенча шөгыльләнеп һәм якынча 62 татарча сүз өйрәнеп, сөйләмдә кулланырга тиеш.

“Минем өем” проекты темалары (“Гаилә”,“Ашамлыклар”,“Уенчыклар”,“Саннар”) буенча бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Аларның тирә-юнь күзаллавын киңәйтә бару, югарыда күрсәтелгән темага караган сүзләр хисабына балаларның сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү, аларда татар телендә сөйләшә башлау теләге уяту.

Актив үзләштерүләренә ирешү өчен әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлату һәм аларны дөрес әйтү күнегүләре эшләү. Иң якын кешеләр (*әти, әни, бабай, әби, малай, кыз)*, яраткан уенчыклар (*туп, машина, курчак, эт, песи куян, аю),* ашамлыклар *(алма, ипи, сөт, чәй)* һәм саннар *(бер, ике, өч, дүрт, биш)* хисабына сүзлекне баету һәм активлаштыру. Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белү күнекмәләрен булдыру. *Алма бир. Мә, алма*.

Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап җавап бирергә өйрәтү.

-*Бу кем? – Бу әти.*

-*Бу нәрсә? – Бу туп.*

Нинди? соравын аңларга, дөрес җавап бирергә өйрәтү.

-*Туп нинди? – Кечкенә.*

-*Машина нинди? – Матур.*

Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауларны аңларга һәм сөйләмдә җавап кайтарырга өйрәтү. (Зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт, пычрак, тәмле).

-*Бу нәрсә? – Бу туп.*

-*Туп нинди? – Туп пычрак (зур, матур, кечкенә, чиста, әйбәт).*

Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны балаларның кабатлап әйтә белүләренә ирешү өстендә эшләү. Аларның өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белүләренә ирешү *(мә, бир, утыр, аша, эч, уйна, ю, ал).*
-*Мә, куян. – Бир куян.*
Тәрбияче әйткән билге буенча предметны табу, күрсәтә белергә өйрәтү.
*Зур машина ал. Тәмле алма бир.*
Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белергә өйрәтү, сүзләрне дөрес, урынлы куллану.
*Исәнме. – Исәнмесез. Сау бул. – Сау булыгыз. Мин кыз. - Мин Оля. Мин малай - Мин Коля.*
Таныш предметларның исемнәрен ныгыту, куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне *(әйе, юк)* дөрес кулланырга өйрәтү
*Син Коля? – Әйе.*
*Син кыз? – Юк, мин малай.*
Мин, син алмашлыкларын аңларга һәм урынлы кулланырга өйрәтү.
*Син кем? – Мин Коля.*
Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар өйрәтү.

**Режим вакытында уен эшчәнлегенең нәтиҗәләре**

Куелган бурычларны төрле ысуллар (дидактик уеннар, саф һавада хәрәкәтле уеннар һ.б.) кулланып татар телен өйрәткәндә көтелгән нәтиҗәләр:
Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап, үти белә.
Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә белә.
Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт әйтә белә.
Куелган сорауларны аңлап, сөйләмдә 2-3 сүз белән җавап кайтара белә.
Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 62 сүз кулланып татар телендә аралаша.
Бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләре бар.
Татар телендә сөйләшү теләге бар.
Әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлый һәм аларны дөрес әйтә белә.
Гаилә, уенчыклар, ашамлыклар һәм саннар хисабына сүз байлыгы бар.
Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белә.
Бу кем? Бу нәрсә? сорауларын аңлап, җавап бирә.

Әйбернең билгесен ачыклау максаты белән куела торган сорауны аңлый һәм сөйләмдә җавап кайтара белә.
Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны кабатлап әйтә. Өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган биремнәрне аңлап үти.
Тәрбияче әйткән билге буенча предметны таба, күрсәтә белә.
Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә, саубуллаша белә, сүзләрне дөрес, урынлы куллана.
Куелган сорауга раслаучы, инкарь итүче сүзләрне дөрес кулланана белә.
Мин, син алмашлыкларын аңлый һәм урынлы куллана.
Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар белә.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**
Сүз байлыгы аз икән.
Бирелгән лексиканы ишетеп аңлый, куллана белми.
Сорауларны аңлый, җавап бирә алмый.
Мин, син алмашлыкларын урынлы куллана белми.

## 2.2. Зурлар төркеме (5-6 яшь)
## “Уйный – уйный үсәбез” проекты

### Белем бирү эшчәнлегенең, режим вакытында уен эшчәнлегенең бурычлары

1. Тирә- юнь күзаллавын киңәйтә барып, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй җиһазлары, ашамлыклар темасына кергән сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру.
2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белүләренә ирешү; үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгуларына ирешү.
3.Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү; боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белү күнекмәләрен үстерү.

### Белем бирү эшчәнлегенең, режим вакытында уен эшчәнлегенең эчтәлеге

**Зурлар төркеме** татар булмаган балалар татар телен атнага бер тапкыр эшчәнлектә, бер тапкыр режим вакытында

шөгыльләнеп якынча 45 (62+45) татарча сүз өйрәнеп, сөйләмдә кулланырга тиеш.
"Уйный-уйный үсәбез" проекты темалары ("Гаилә", "Ашамлыклар", "Уенчыклар", "Саннар" **, "**Яшелчәләр", "Савыт-саба", "Киемнәр", "Шәхси гигиена", "Өй җиһазлары", "Бәйрәмнәр") буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.
Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру. (*Кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, аш, ботка, кашык, тәлинкә,чынаяк, күлмәк, чалбар, бит, кул, өстәл урындык, карават, баллы, ничә, нинди, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кызыл, сары, яшел, зәңгәр, нәрсә кирәк, юа, ки, сал, йокла, хәерле көн, яратам, бар).*
Санау күнекмәләрен ныгыту, сөйләмдә камилләштерү.
Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.
Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне ныгыту, урынлы куллану. *(Әйе, юк)*
Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә активлаштыру.
- *Бу кызыл тәлинкә.*
"Минем өем" проекты буенча өйрәнелгән боерык фигыльләрне ныгыту *(аша, эч, утыр, ю, уйна, йокла)*, яңа боерык фигыльләрне *(ки, сал)* сөйләмдә аңлап дөрес куллана белергә өйрәтү, активлаштыру.
Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең, режим вакытында уен эшчәнлегенең нәтиҗәләре**

Куелган бурычларны төрле ысуллар кулланып татар телен өйрәткәндә көтелгән нәтиҗәләр:
Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белү.
Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта107 сүз кулланып татар телендә аралашу.
Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллану.
Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап, дөрес куллану.
"Уйный-уйный үсәбез" проекты темалары ( "Гаилә", "Ашамлыклар", "Уенчыклар", "Саннар" **, "**Яшелчәләр", "Савыт-саба", "Киемнәр", "Шәхси гигиена", "Өй җиһазлары", "Бәйрәмнәр") буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белү, сөйләм күнекмәләре бар.
Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.
Санау күнекмәләре бар, сөйләмдә куллана белү.
Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирү.

Раслаучы һәм инкарь итүче сүзләрне аңлау, урынлы куллану.
Исем + сыйфат конструкциясен сөйләмдә дөрес куллану.
Боерык фигыльләрне сөйләмдә аңлап дөрес куллана белү.
Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана белү.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**
Сүз байлыгы аз.
Бирелгән лексиканы ишетеп аңлый, куллана белми.
Сорауларны аңлый, мөстәкыйль рәвештә сорау куя белми.
Сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә куллана алмый.

## 2.3. Мәктәпкә әзерлек төркеме (6-7 яшь)
### “Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар”проекты
### Белем бирү эшчәнлегенең, режим вакытында уен эшчәнлегенең бурычлары

1. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү. Ашамлыклар, кыргый хайваннар, кошлар, мәктәп темасына кергән сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру.
2. Диалогик һәм монологик сөйләмне үстерү.
3. Мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә күнектерү.

### Белем бирү эшчәнлегенең, режим вакытында уен эшчәнлегенең эчтәлеге

**Мәктәпкә әзерлек төркеме** татар булмаган балалар татар телен атнага ике тапкыр эшчәнлектә, бер тапкыр режим вакытында шөгыльләнеп якынча 60 (62+45+60) татарча сүз өйрәнеп, сөйләмдә кулланырга тиеш.
“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” **,** **“**Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият яратабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру: *син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем, бу нәрсә, нишли, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың, син нишлисең, сикер-сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер-йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла-җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр.*
Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.
Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү. Монологик сөйләмне үстерү.

**Белем бирү эшчәнлегенең, режим вакытында уен эшчәнлегенең нәтиҗәләре**

Куелган бурычларны төрле ысуллар кулланып татар телен өйрәткәндә көтелгән нәтиҗәләр:
Сөйләмне аралашу чарасы буларак файдалана белә.
Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре бар.
Мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.
Бер-берсе һәм өлкәннәр белән 167 сүз кулланып татар телендә актив аралаша.
“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар” проекты темалары ( “Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар” , “Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият яратабыз”) буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (танып – белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт) ишетеп аңлап куллана белә, сөйләм күнекмәләрен бар.
Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы бар.
Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың? соравын аңлап, мөстәкыйль рәвештә сорау куя һәм дөрес җавап бирә белә.
Фигыльләрне урынлы куллана.
Җырлар, шигырьләр белә.

**Тәрбияче һәм ата- аналар белән берлектә ирешергә кирәк нәтиҗәләр:**
Яңа сүзләр хисабына сүз байлыгы булдыру.

Бирелгән лексиканы диалогик һәм монологик сөйләмдә  куллана алу.
“Бу кем?”, “Бу нәрсә?”, “Нәрсә кирәк?”, “Нинди?”, “Ничә?”, “Нишли?”, “Син нишлисең?” “Кая барасың?” сорауларын мөстәкыйль рәвештә  куя белми. Фигыльләрне урынлы куллана белү.

## 2.4 Программа түбәндәге принципларга таянып төзелде:

*Коммуникативлылык принцибы* – балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерли. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтә.

*Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашыру принцибы.* *Дәвамчанлык принцибы* – балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тота;

*Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы* – бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлавында.  Телне өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу) белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашу, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм  алар тел материалын бик теләп үзләштерәләр.

*Индивидуальләштерү принцибы* – тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тота. Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә ала.

*Күрсәтмәлелек принцибы* – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрә;

*Интеграция принцибы* – һәр сөйләм төренең үз үзәнчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио-, видеоязмада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү;

## Балаларның яшь үзенчәлекләре

Мәктәпкәчә чорны шартлы рәвештә берничә этапка бүлеп чыгарырга мөмкин:
Беренче этап (2-3 яшь). Хис-тойгы, эмоцияләр җыю чоры. Бу этапта иң мөһиме – хисне уяту. Сәнгать алымнары бу яшь аралыгында бары үсеш фоны буларак кулланыла.
Икенче этап (3-4 яшь). Табигый сәләтнең беренчел сыйфатлары күзәтелә. Әлеге яшьтәге бала шактый актив, теләсә кайсы эшчәнлеккә теләп, яратып алына. Шушы фактны истә тотып, балаларга берничә өлкәгә караган эш төрләрен тәкъдим итәргә һәм һәр баланы күзәтергә кирәк.

Өченче этап (4-5 яшь). Кызыксыну, теләк, иҗади эзләнү хас чор. Бу этапта сәләтләре бертөрлерәк булган балаларны өстәмә дәресләр өчен төркемнәргә берләштерергә ярый.
Дүртенче этап (5-6 яшь). Табигый сәләтенең ачык күренеп торуы белән характерлана.
5-6 яшьтәге бала бу чорда эшне уңышлы һәм нәтиҗәле итеп башкарырга омтылалар.
Бишенче этап (6-7 яшь). Профессиональ сәнгатькә беренче адым ясау вакыты. Бу этапта аерым бер балаларның сәләтләре, ачык күренеп, зур үсеш ала. Шуңа күрә аларга өстәмә шөгыль-чаралар тәкъдим итү, башлыча, төрле түгәрәкләр оештыру зарур. Аерым бер балалар белән индивидуаль эш итү дә бик үтемле бу чорда. Болар барысы да баланың табигый сәләтен үстерү өчен ярдәмче фактор. Баланың сәләтләре үсешендә бишенче этап – мәктәпкә әзерлек төркеме. Аерым бер балаларның үсеш дәрәҗәсе шактый югары була. Бу вакытта балаларның эшчәнлек даирәсен киңәйтеп, алга таба эстетик һәм интеллектуаль үсеш өчен шартлар булдыру мөһим.

## 2.5 Эш төрләре һәм формалары.

Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1. Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.
2. Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.
3. Сюжетлы-рольле уеннар;
4. Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
5. Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).
6. Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, “Командир” уены, әйлән-бәйлән уен, зарядка уеннары.
7. Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
8. Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
9. Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
10. Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.
11. Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.
12. Интерактив уеннар.

## 2.6 Ата- аналар белән эш

- Икенче кечкенәләр төркеменә яңа килгән татар милләтеннән булган балаларның ата – аналары белән анкета үткәрү.
- Ата – аналар җыелышында чыгышлар ясау.

- Консультацияләр үткәрү.
- Ачык ишекләр көне үткәрү.
- Балалар бакчасының сайтында информацияләрне яңартып тору.
- “Татарча сөйләшәбез – Говорим по – татарски” папкаларындагы информацияләрне яңартып тору.
- Индивидуаль консультацияләр бирү, әңгәмәләр үткәрү.
- Ата- аналарның, балаларның рәсемнәре күргәзмәсе үткәрү.

## 2.7 Педагогик коллектив белән эш

- Педагоглар өчен татар теленә өйрәтү эшчәнлекләре үткәрү.
- Педагогик киңәшмәләрдә чыгышлар ясау.
- Консультацияләр бирү.
- Төркем тәрбиячеләре һәм белгечләр белән берлектә бәйгеләр үткәрү.
- Ачык ишекләр көнендә эшчәнлек күрсәтү.

## 2.8 Мәктәп белән бәйләнеш

- Мәктәп һәм бакча  балалары белән уртак бәйрәмнәр үткәрү.
- Ата- аналар җыелышларына мәктәп укытучыларын чакыру.
- Үзара эшчәнлек һәм дәресләр карау.

## ФДС тормышка ашыру

| | | |
|---|---|---|
| ***Социаль-коммуникатив үсеш*** | - сюжетлы-рольле уеннар<br>- әңгәмәләр<br>- видеофильмнар карау<br>- кизүлек<br>- уен барышында куркынычсызлык кагыйдәләрен үтәү | Туган як табигате, үсемлекләре, җәнлекләре белән танышу; сулыкларда сак булырга өйрәтү; экологик культура, табигатькә аңлы караш тәрбияләү |
| ***Танып- белү*** | - экскурсияләр<br>- дәфтәрләрдә эш<br>- предметларны санау,төсен, формасын, зурлыгын әйтү | Нәфис сүз, халык авыз иҗаты, әдәби әсәрләр, милли бәйрәмнәр аша балаларның сөйләм телен баету, уй-фикерләрен билгеле бер эзлеклелектә җиткерә белүләренә ирешү |
| ***Сөйләм үсеше*** | - әкиятләр сәхнәләштерү<br>- шигырьләр уку<br>- мультфильмнар карау<br>- ситуатив күнегүләр<br>- сюжетлы-рольле уеннар<br>- хикәяләр төзү<br>- әңгәмәләр | Сөйләмне  аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.<br>Гади диалогта катнаша белү, хәтер, зиһен үстерү.<br>Гади сорауларны аңлап  җавап  бирү,  мөрәҗәгать итә  белү, көндәлек  яшәештә  аралашу. |
| ***Нәфис- нәфасәти үсеш*** | - дәфтәрләрдә эш<br>- рәсем ясау, ябыштыру, әвәләү<br>- җырлар<br>- музыкаль-дидактик уеннар<br>- җырлы-биюле уеннар<br>- драма уеннары | Балаларның милли сынлы сәнгать турындагы белемнәрен баету, татар һәм Идел буе халыкларының декоратив-гамәли сәнгать үрнәкләре белән таныштыру, милли орнамент белән кием-салым, савыт-саба бизәргә өйрәтү; күренекле композиторларның, төрле халыкларның җырлары, биюләре, музыкаль инструментлары белән танышу. |
| ***Физик үсеш*** | - үзмассаж туплары белән уеннар<br>-сәламәтлек сукмагы<br>- хәрәкәтле уеннар<br>- зиһен сынаш уеннары<br>- җырлы-биюле уеннар | Идел буе халыкларының хәрәкәтле уеннары аша балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту |

**Лингвистик материал сайлау схемасы**
**Социаль контактлар, аралашу сфералары, ситуацияләрне ачыклау**
**Сөйләшү, сөйләм предметын билгеләү**
**Сөйләм бурычларын ачыклау**
**Тиешле лингвистик материалны сайлау.**

Әлбәттә, эчтәлек сайлаганда сөйләм материалының күләмен билгеләү өчен балаларның психо-физиологик мөмкинлекләрен исәпкә алу зарур. Югарыда әйтелгәннәрне искә алып сайланган материал балалар бакчасында телгә өйрәтү шартларын телне тормышта куллану шартларына якынлаштыру мөмкинлеген тудыра.

**Телне өйрәнү процессын индивидуальләштерү принцибы.**

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар эмоциональ, хәрәкәтчән, тиз арыйлар. Бала материалны үзе өчен кызык булса гына, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килсә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү процессында әкияти, фантастик сюжетлар, кызыклы геройлар белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын ойрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Материалны кат-кат кабатлап, ятлап өйрәнүгә караганда, аралашу ситуацияләрендә сөйләм бурычына тәңгәл килгән лексик – грамматик материалны балаларның мөстәкыйль комбинацияләп сөйләшүе – тел өйрәнү өчен күп мәртәбә нәтиҗәлерәк алым. Димәк, эчтәлектә аралашу ситуацияләре һәм ситуатив күнегүләр системасы булу мәҗбүр. Телне аралашу ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен шундук тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм тел өйрәнү процессының мотивлашкан булуын тәэмин ителә. Икенче телне өйрәнү вакытында бала, ихтыярсыз рәвештә, лингвистик материалны ана теле күренешләре белән чагыштыра. Бу – телне үзләштерү процессын җиңеләйтә. Димәк, һәр шөгыльгә программа материалын сайлаганда, балаларның ана теле буенча белемнәр системасын исәпкә алу зарур.

Шөгыльләрдә ситуатив күнегүләрнең рус һәм татар телендә бирелүе балаларның белем сыйфатын күтәрүгә зур этәргеч булып тора. Комплектларның төп максаты балаларны аралашуга өйрәтү.

**Укыту методик кулланма (УМК) өч проекттан тора һәр проект өчен:**

1) тематик план;
2) календарь – көндәлек план;
3) балалар өчен эш дәфтәрләре;
4) аудиоматериаллар;
5) мультипликацион сюжетлар;
6) күрсәтмә, таратма материаллар исемлеге;

7) диагностика төзелгән.

| №П/П | ЯШЬ АРАЛЫГЫ | АКТИВ (пассив) СҮЗЛӘР | СҮЗЛӘР САНЫ |
|---|---|---|---|
| 1. | 4-5 яшь | **Актив сүзләр:** әти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш. (49 сүз)<br><br>**Пассив сүзләр:** утырыгыз, бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә? нинди? (13 сүз) | **62 сүз** |
| 2. | 5-6 яшь | **Актив сүзләр:** кишер, нинди, баллы, ничә, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, караваt, яратам, бар (38 сүз)<br><br>**Пассив сүзләр:** бу нәрсә?, хәерле көн, нәрсә бар? күп (7 сүз) | **45 сүз** |
| 3. | 6-7 яшь | **Актив сүзләр:** син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем? бу нәрсә? нишли?, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең?, ашыйм, эчәм, уйный,<br><br>уйныйм, утырам, барам, кая барасың?, син нишлисең?,сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр (58 сүз)<br><br>**Пассив сүзләр:** нәрсә яратасың? (2 сүз) | **60 сүз** |

**Тәрбиячеләр өчен язылган методик кулланмада:**

1) Тематик план,
2) Шөгыльләр конспекты,
3) Диагностика .

**Бу укыту методик кулланмалар нәрсә белән аерыла соң?**

Бүгенге көндә балаларны татар теленә өйрәткәндә кулланыр өчен эш дәфтәрләре, аудиоматериаллар, мультипликацион сюжетлар булмады. Өч төркем өчен дә эш дәфтәрләре ясалган. Аларның эчтәлеген, биремнәрен, нинди рәсемнәр куллануны уйлап. Аудиоматериал, мультипликацион сюжетларның эчтәлеген шөгыльләргә туры китереп эшләнгән.

Эш дәфтәрләре, аудиоматериал һәм мультипликацион сюжетлар һәр шөгыльдә дә кулланылмый. Кулланылган очракта шөгыльнең бер өлеше булып бара.

**Мультипликацион сюжетлар** өченче шөгыльдә карау өчен уйлап эшләнелгән. Эчтәлеге 3-7 минут. Алар балаларның белгән сүз байлыгын, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән. Берничә шөгыль узгач өйрәнгән сүзләр һәм алдагы шөгыльләрдә сөйләмдә куллануга кертелә торган яңа сүзтезмәләр дә кулланыла.Бу мультипликацион сюжетларны караганнан соң балалар белән сорау – җавап тибында әңгәмәләр үткәрелә, вакыт калса алда өйрәнелгән уеннарны кабатларга тәкъдим ителә.

**Аудиоматериаллар:** танышу, яңа сүз, өйрәткәндә, диалог, сөйләм үрнәкләре, уеннар, кыска җырлар, өстәл театры күрсәткәндә куллану өчен төзелгән.

**Эш дәфтәрләре** шөгыльдә өйрәнелгән материалны ныгытуны күздә тотып төзелгән. Дәфтәрләр белән эшләгәндә балалар кабатлыйлар, бер-берсенә сораулар бирәләр, тәрбияче белән аралашалар. Бик уңай ягы, балалар үзләренең шөгыльдә эшләгән дәфтәрләрен өйгә алып кайтып кабатлый алалар. Бу дәфтәрләр белән әти-әниләр дә, төркемдә эшләгән тәрбиячеләр дә эшли ала, чөнки биремнәр рус телендә язылган.

Педагогикага багышланган әдәбиятне карап чыкканнан соң, нинди дә булса бер чараны гына алып, менә монысы гына тел өйрәнү өчен иң куәтлесе, иң кирәклесе, дип берсен генә аерып әйтеп булмый. Һәрбер автор төрле чараны атый

Һәм шуңа да, укыту-методик комплектының, күргәнегезчә, юнәлешләре күптөрле. Алар балалар өчен кызыклы һәм мавыктыргыч итеп эшләнелгән. Һәрбер юнәлеш билгеле бер үзенең максатын чишә. Билгеләп үтелгәнчә, гамәли дәфтәрләр, яки эш дәфтәрләре – заманча төзелгән укыту-методик комплектының төп юнәлешләренең берсе булып тора.

Дәфтәрләр балаларның педагог тарафыннан оештырылган эшчәнлектә алган белемнәрен ныгыту максатында куллану өчен тәкъдим ителә.

**Эш дәфтәренең дидактик функцияләре:**

1) Компенсаторная (компенсатор) – яки бу балаларга сүз өйрәтү процессын җиңеләйтү, баланың һәм тәрбияченең көчен һәм вакытын экономияләү дигән сүз. Ниндидер дәрәҗәдә сәламәтлекне саклау аспектына да кагылып кителә. Тәрбияче белән балалар күмәк эшли, ә балалар исә эшчәнлек төрен үзгәртәләр.

2) Информативная (информатив) – яки балалар өчен иң кирәкле информацияне җиткерү;

3) Интегративная (интегратив) – өйрәнү объектын өлешләп һәм бербөтен итеп карау;

4) Познавательная (танып-белү) – баланың танып-белүен үстерү, яки күзәтүчәнлек, уйлау, эстетик матурлыкны күрә белүе;

5) Формирующая (формалаштыру)- баланың материалны үзләштерүе, танып –белү алымнары формалашуы.

Дәфтәрдәге эшнең нәтиҗәсе уртанчылар төркемендә сүзне ишетеп, аңлап, предметларны табып, парлаштырып, чагыштырып, аларның сыйфатын, санын билгеләүгә китерсә, зурлар төркемендә балаларны үзара аралашуга этәрә һәм бу мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә дәвам итә. Иң катлаулы биремнәр мәктәпкә әзерлек төркеме өчен төзелгән.

Бу төркемдә хәрәкәтне белдерүче сүзләр, яки фигыльләр күп кулланыла. Балаларны ситуацияләргә куеп, сораулар биреп диалогка этәрәбез. Берүк вакытта, фигыльләр боерык формада (утыр, уйна һ.б.), 2-нче зат алмашлыгына тәңгәл формада (яки утыра, укый, шуа, ашый һ.б.), һәм дә инде үзе турында 1-нче зат алмашлыгын кулланып өйрәтелә (уйныйм, утырам, барам, эчәм). Шулай ук балалар күп кенә сораулар куярга өйрәнәләр: бу нәрсә, нишли, син нишлисең, нәрсә кирәк, нинди һ.б. Җөмләләр төзү баланың уйлавын таләп итә, чөнки алар 3-4 сүздән торалар.

Нинди дә булса күзаллау булсын өчен, эш дәфтәрләрен интерактив тактага ясалган. Интерактив такта булган бакчалар өчен бу биремнәрне тактага күчерергә тәкъдим ителә, чөнки бу очракта, дәфтәрләрне балаларның үзләренә бирергә мөмкинлек туа, алар өйләрендә әти-әниләре белән бергәләп эшли алалар.

**“Минем өем” проекты буенча тематик план**
**(Уртанчылар төркеме )**

| № | Темалар | Сәгать |
|---|---|---|
| 1 | **Гаилә** | **26** |
| | “Минем гаиләм” | 2 |
| | “Малай, кыз” | 2 |
| | “Минем туганнарым” | 1 |
| | “Әйдәгез танышыйк” | 3 |
| | “Тату гаилә” | 2 |
| | “Минем дуслар” | 3 |
| | “Әйдәгез дуслашыйк” | 1 |
| | “Әйе, юк” | 3 |
| | “Качышлы уйныйбыз” | 1 |
| | “Кунак килгән” | 3 |
| | “Әйдәгез уйныйбыз” | 1 |
| | “Безнең кунаклар” | 3 |
| | “Шалкан әкияте” | 1 |
| 2 | **Ашамлыклар** | **20** |
| | “Әби күчтәнәче” | 2 |
| | “Бабай күчтәнәче” | 2 |
| | “Безнең кунаклар” | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | “Сөт, чәй” | 2 |
| | Дустыңны сыйла” | 2 |
| | “Рәхмәт әйт” | 1 |
| | “Песине сыйла” | 2 |
| | “Кунак сыйлау” | 2 |
| | “Тәмле” кибетендә | 1 |
| | “Кунакны ашат” | 2 |
| | “Чәй табынында” | 2 |
| | “Азат кунак чакыра” | 1 |
| 3. | **Уенчыклар** | **31** |
| | “Уенчыклар” | 2 |
| | “Зур, кечкенә” | 2 |
| | “Күңел ачу кичәсе – “Туган көн” | 1 |
| | “Курчак кунакка килгән” | 2 |
| | “Уенчыклар кибете” | 2 |
| | “Паркка сәяхәт” | 1 |
| | “Яңа уенчыклар” | 2 |
| | “Уйныйбыз” | 2 |
| | “Без уйнарга яратабыз” | 2 |
| | “Мияуга бүләк” | 1 |
| | “Уенчыклар кибете” | 3 |
| | “Уенчыклар үпкәләгән” | 1 |
| | “Бүләкләр” | 2 |

| | | |
|---|---|---|
| | “Уйна” | 2 |
| | “Күңелле уеннар” | 1 |
| | “Уенчыклар юабыз” | 2 |
| | “Ю” | 2 |
| | “Акбай һәм мияу маҗаралары” | 1 |
| 4. | **Саннар** | **10** |
| | “Саннар” | 3 |
| | “Уйныйбыз да , саныйбыз да” | 2 |
| | “Уенчыклар” | 2 |
| | “Ничә уенчык?” | 2 |
| | “Уйный-уйный саныйбыз” | 1 |
| 5. | **Габдулла Тукай** | **3** |
| 6. | **Кабатлау** | **12** |
| | “Бергәләп уйныйбыз” | 2 |
| | “Кунак чакырабыз” | 2 |
| | “Күңелле ял итәбез” | 1 |
| | “Без татарча сөйләшәбез” | 3 |
| | “Бу өйдә кем яши ?” | 3 |
| | “Без театр уйныйбыз” | 2 |
| | **Барлыгы:** | 103 |

**“Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча тематик план**
**(Зурлар төркеме)**

| № | Темалар | Сәгать |
|---|---|---|
| 1 | **Минем өем – Мой дом** | **5** |
| | “Минем өем” | 2 |
| | “Кем юк?” | 2 |
| | “Мультфильм «Шалкан» әкияте” | 1 |
| 2. | **Яшелчәләр – Овощи** | **36** |
| | “Кишер үстерәбез” | 2 |
| | “Куян күчтәнәче” | 1 |
| | “Баллы кишер”- мультфильм | 1 |
| | “Серле кәрзин” | 2 |
| | “Сыйлыйбыз” | 2 |
| | “Бар матур бакча” | 2 |
| | “Серле янчык” | 2 |
| | “Серле кәрзин” | 2 |
| | “Бар матур бакча” | 2 |
| | “Без хезмәт яратабыз” | 2 |
| | “Яшелчәләр кибете” | 2 |
| | “Уйный-уйный эшлибез” | 1 |
| | Төсләр дөньясы - Цвета | 4 |

| | | |
|---|---|---|
| | Юл маҗаралары - мультфильм | 1 |
| | “Яшелчә салаты” | 2 |
| | “Яшелчә ю” | 2 |
| | “Кем эшләми, шул ашамый”-мультфильм | 1 |
| | “Яшелчәләр кибете” | 2 |
| | “Уйныйбыз да, җырлыйбыз да” | 2 |
| | “Уңыш бәйрәме” | 1 |
| 3. | **Ашамлыклар – Продукты** | **10** |
| | “Ашамлыклар” | 2 |
| | “Ашханә” | 2 |
| | “Аш бүлмәсе”-мультфильм | 1 |
| | “Аю кунакка килгән” | 1 |
| | “Кибеттә” | 2 |
| | “Кем нәрсә ярата?” | 2 |
| 4. | **Савыт- саба - Посуда** | **10** |
| | “Туган көн” | 2 |
| | “Курчак Алиягә булыш” | 2 |
| | “Өч аю”-мультфильм | 1 |
| | “Чәй табыны әзерлибез” | 2 |
| | “Төсле чынаяклар” | 2 |
| | “Чисталыкта матурлык”- мультфильм | 1 |
| 5. | **Киемнәр – Одежда** | **9** |

| | | |
|---|---|---|
| | “Туган көнгә яңа киемнәр”<br>“Курчакны киендер”<br>“Без киенәбез”<br>“Киенергә ярдәм ит”<br>“Алия йокларга җыена”<br>“Шаян уенчыклар” | 1<br>2<br>1<br>2<br>1<br>2 |
| 6. | **Шәхси гигиена** | **5** |
| | “Хәерле көн”<br>“Курчак белән уйныйбыз”<br>“Ни өчен киемнәр югалган?”- мультфильм | 2<br>2<br>1 |
| 7. | **Җиһазлар – Мебель** | **5** |
| | Өстәл театры “Өч аю”<br>“Җиһазлар кибете”<br>“Маша һәм өч аю”- мультфильм | 2<br>2<br>1 |
| 8. | **Бәйрәм “Туган көн”** | **14** |
| | “Уенчыклар иленә сәяхәт”<br>“Курчакның туган көне”<br>“Туган көн”<br>“Уйнарга яратабыз” | 1<br>2<br>1<br>2 |

| | | |
|---|---|---|
| 9. | “Син нәрсә яратасың?”<br>“Кем нәрсә ярата?”<br>“Уйный-уйный үсәбез”<br>“Нәрсә бар?”<br>“Бар, юк”<br>**Габдулла Тукай**<br>**Бәйрәм “Сабантуй”**<br>“Сабантуйга әзерләнәбез”<br>“Күңелле Сабантуй уеннары”<br>“Сабантуй бәйрәме”<br><br>**Барлыгы :** | 2<br>1<br>1<br>2<br>2<br>**3**<br>**6**<br>2<br>2<br>2<br><br>**103** |

**“Без инде хәзер зурлар – мәктәпкә илтә юллар”**
**проекты буенча тематик план**
**(Мәктәпкә әзерлек төркеме)**

| № | Темалар | Сәгать |
|---|---|---|
| 1 | “Әйдәгез танышабыз” | 1 |
| 2 | “Хәерле көн” | 3 |
| 3 | Мультфильм“Мияу адашкан” | 1 |
| 4 | “Син кем?” | 3 |
| 5 | “Шалкан” әкиятен сәхнәләштерү | 2 |
| 6 | “Аю балсы дөнья белән таныша” | 1 |
| 7 | “Бу нәрсә?” | 2 |
| 8 | “Кем нишли?” | 2 |
| 9 | “Батыр Мияу белән куркак Куянкай” | 1 |
| 10 | “Дусларны сыйлыйбыз” | 2 |
| 11 | “Нишлисең?” | 2 |
| 12 | “Тату гаилә” | 1 |
| 13 | “Әйдәгез уйныйбыз” | 2 |
| 14 | “Кунак килде” | 2 |
| 15 | “Юмарт аю” | 1 |
| 16 | “Кафега барабыз” | 2 |
| 17 | “Без кафеда” | 2 |
| 18 | Мультфильм “Кафега барабыз” | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 19,20 | “Күңелле уеннар” | 4 |
| 21 | Мультфильм “Күңелле уеннар” | 1 |
| 22 | “Спорт бәйрәменә әзерләнәбез” | 2 |
| 23 | “Бәйрәмгә барабыз” | 2 |
| 24 | Мультфильм “Көчлеләр, кыюлар, җитезләр” | 1 |
| 25 | “Казанда спорт бәйрәме” | 2 |
| 26 | “Без циркта” | 1 |
| 27 | Мультфильм “Җәнлекләр спорт бәйрәмендә” | 1 |
| 28 | “Безнең дуслар” | 2 |
| 29 | “Үрдәк дусларын тапты” | 2 |
| 30 | Мультфильм “Циркта” | 1 |
| 31 | “Акбай чана шуа” | 3 |
| 32 | “Чана шуам” | 2 |
| 33 | Мультфильм “Шаян кошлар” | 1 |
| 34 | “Әйдә бие” | 1 |
| 35 | “Без биибез” | 2 |
| 36 | Мультфильм “Урманда зур концерт” | 1 |
| 37 | “Мияуның бүлмәсен бизибез” | 2 |
| 38 | “Туган көнгә бүләк әзерлибез” | 2 |
| 39 | Мультфильм “Акбай туган көнгә барырга әзерләнә” | 1 |
| 40 | “Мияуның туган көне” | 2 |
| 41 | “Туган көн табынында” | 1 |
| 42 | Мультфильм “Мияуның туган көне” | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| 43,44 | “Күңелле сәяхәт” | 4 |
| 45 | Мультфильм “Урман китапханәсендә” | 1 |
| 46 | “Күңелле сәяхәт” | 5 |
| 48 | Мультфильм «Уйный-уйный укыйбыз» | 1 |
| 49 | “Мәктәптә” | 1 |
| 50 | “Уку бүлмәсе” | 2 |
| 51 | Мультфильм “Урман мәктәбендә” | 1 |
| 52 | Өстәл театры “Теремкәй” | 1 |
| 53 | “Теремкәй” әкиятен сәхнәләштерү | 2 |
| 54 | “Теремкәй” мультфильм | 1 |
| 55 | Өстәл театры “Кем нәрсә ярата?” | 1 |
| 56 | “Кем нәрсә ярата?” әкиятен сәхнәләштерү | 2 |
| 57 | Мультфильм “Кем нәрсә ярата?” | 1 |
| | **Габдулла Тукай** | **3** |
| 58 | “Белем иленә сәяхәт” | 2 |
| 59 | “Могҗизалар кыры” | 2 |
| 60 | “Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар” | 4 |
| **Барлыгы:** | | **103** |

**3.Диагностика .**

Түбәндәге биремнәрне балаларның татар телен белү дәрәҗәсен билгеләгәндә кулланырга мөмкин. Тикшерү һәр бала белән аерым үткәрелә, ул 5 – 10 минуттан артмаска тиеш. Ә йомгаклау дәресе булганда, тикшерүне барлык балалар белән бергә үткәрергә мөмкин. Биремнәр уен формасында рус телендә аңлатыла. Балаларның җавабын тыңлаганда тикшерүче елмаеп, кирәк булса, җавапны дөресләп, бала әйтә алмаган очракта, булышырга тиеш.

Тикшерү нәтиҗәләрен түбәндәгечә таблицага төшерергә мөмкин.
Нәтиҗәгә карап, тәрбияче, һәр бала белән эшләү өчен, бурычлар билгеле.

**Уку елы ахырында уртанчылар, уку елы башында зурлар төркеме балаларының “Минем өем” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

| № | Балаларның исем, фамилиясе | Сүз байлыгы | | Бәйләнешле сөйләм | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | “Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча дүрт – биш рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”) | Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч) | Тирә - юньдәге предметларның сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану. | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сарап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) |
| 1. | Коля | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | |

**Нәтиҗәләрне билгеләү**

| | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә<br>2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, сорауларга җавап бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә<br>2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, аралашуда бик үк актив түгел. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә<br>1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**Уку елы ахырында зурлар, уку елы башында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының “Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

| № | Балаларның исем, фамилиясе | **Сүз байлыгы** | | **Бәйләнешле сөйләм** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | “Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”. “исәнмесез”, “ сау булыгыз”) | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) |
| 1. | Коля | | | | | |

**Нәтиҗәләрне билгеләү**

| | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә<br>2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә<br>2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә<br>1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**Уку елы ахырында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

| № | Балаларның исем, фамилиясе | **Сүз байлыгы** | | **Бәйләнешле сөйләм** | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “исәнмесез”, “сау бул”, “сау булыгыз”, “рәхмәт”, “зур рәхмәт”, “хәерле көн”, “хәлләр ничек?”, “әйбәт”) | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал, бие, җырла, йөгер, йокла) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Кая барасың?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь иү, раслау) |
| 1. | Коля | | | | | |

**Нәтиҗәләрне билгеләү**

| | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә<br>2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә<br>2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә<br>1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**Кулланылган әдәбият**


1. Төбәкнең мәктәпкәчә белем бирү программасы. Шаехова Р.К.
Казан, 2012 ел.

2. “Татарча сөйләшәбез”. 4-5 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча ярдәмлек.
З. М. Зарипова җитәкчелегендәге иҗади төркем. Казан, 2012ел.

3. “Татарча сөйләшәбез”. 5 - 6 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча ярдәмлек.
З. М. Зарипова җитәкчелегендәге иҗади төркем. Казан, 2012ел.

4. “Татарча сөйләшәбез”. 6 - 7 яшьлек балаларны татар теленә өйрәтү буенча ярдәмлек.
З. М. Зарипова җитәкчелегендәге иҗади төркем. Казан, 2012ел.

5. “Балачак аланы”-балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия.
К. В. Закирова. Казан, 2011ел.

6. “Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак” –балалар бакчасында уеннар К.В. Закирова, Мортазина. Казан, 2012ел.

7. *Зарипова З.М.* Татарча сөйләшәбез (4-5 яшьлек балаларга татар теле өйрәтү): методик кулланма. – Казан, 2012ел.

8. *Закирова К.В.* Балачак аланы: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм эти-әниләр өчен хрестоматия. – Казан, 2011ел

9. *Закирова К.В.* Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе: методик кулланма. – Казан, 2013ел.

10. *Закирова К.В., Мортазина Л.Р.* Балачак – уйнап-көлеп үсәр чак: балалар бакчасында уеннар: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма. – Казан, 2012ел.

11. *Зарипова З.М., Исаева Р.С.* Үстерешле уеннар: методик кулланма. – Казан, 2013ел.

12. *Закирова К.В., Мортазина Л.Р.* Әй уйныйбыз, уйныйбыз ...: Балалар бакчасында хәрәкәтле уеннар: балалар бакчасы тәрбиячеләре һәм физкультура инструкторлары өчен методик кулланма. – Казан, 2013ел.

13. *Гарәфиева Г.З.* Сөмбеләне кем белә?/ Балалар бакчалары тәрбиячеләре һәм музыка җитәкчеләре өчен методик ярдәмлек. – Казан, 2003ел.

14. *Исаева Р.С.* Методическое пособие для воспитателей (по обучению детей татарскому языку), групповых воспитателей

“200 игр” I часть по проекту «Растём играя» - 34 стр.

15. *Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ.* Туган телдә сөйләшәбез: методик әсбап 4-5яшь – Казан, 2013ел .

16.*Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ.* Туган телдә сөйләшәбез. Методик кулланма 3-4 яшь – Казан, 2013ел .

**Аудиокушымта:**

1. *Закирова К.В., Кадырова Р.* Балалар бакчасында әдәп-әхлак тәрбиясе: методик әсбап өчен аудио-кушымта. – Компания “АКСУ”, 2013.

2. *Хәзрәтова Ф.В., Шәрәфетдинова З.Г., Хәбибуллина И.Җ.* Туган телдә сөйләшәбез: балалар бакчасында татар телендә тәрбия һәм белем бирү (уртанчылар төркеме): методик кулланма өчен аудио-кушымта. – Компания “АКСУ”, 2013.

3. Җырлап биеп уйныйбыз: мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен җырлы-биюле уеннар аудиоҗыентыгы.